УДК 398=512.145

***Л.Х. Дәүләтшина***

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ДИНИ-МИФОЛОГИК КҮЗАЛЛАУЛАРЫ
## (материал туплау өчен сораулык)

Публикуется вопросник для сбора материала по традиционным религиозно-мифологическим представлениям татар, освещающий основные термины; категории мифологических персонажей, их функции; представления, связанные с окружающим миром, смертью, душой, магическими практиками. Основа вопросника – собственный полевой опыт автора и опубликованные источники.

**Ключевые слова:** традиция, обряд, мифология, мифологические представления, мифологический персонаж, верования.

Мифология халык иҗатының иң борынгы катламын тәшкил итә. Күп гасырлар элек, кешенең әйләнә-тирә дөнья, тирәлек турындагы фантастик күзаллаулары нигезендә, күпсанлы ышанулар, йола-ритуаллар туган. Кеше әле бу вакытта үзен табигать дөньясыннан аерып карамаган һәм әйләнә-тирәсендәге барлык җанлы һәм җансыз әйберләрне «җанландырган», аларны үзе кебек яши, кайгыра, көлә, сөйләшә белә дип исәпләгән. Утның да, суның да, җирнең дә җаны бар дип уйлау төрле аллалар һәмияләр турындагы ышануларның барлыкка килүенә сәбәп булган.

Фольклористикада татар халкының мифологик мирасын югары мифологиягә һәм түбән мифологиягә бүлеп карау кабул ителгән [Бакиров, Урманчеев]. Югары мифология мәҗүси Аллалар (Тәңре, Җир-Су, Умай, Алас һ.б.) турындагы ышанулар һәм хикәятләр берлегеннән гыйбарәт булса, түбән мифология Алла статусына ия булмаган ияләрне, кара көчләрне һәм рухларны берләштерә. Ияләр табигать объектларының, кеше яши торган торак урыннарының хуҗасы буларак кабул ителә һәм, күңелләрен күрә белсәң, кешегә файдалы затлар буларак күзаллана. Җен, албасты, убыр, өрәк, шүрәле һ.б. шундый түбән рухлар адәм баласының тормышында туган күңелсезлек, бәхетсезлек, акылдан язу, адашу кебек күренешләрнең сәбәпчесе итеп уйланыла.

Бүгенге көндә югары мифологиягә караган аллалар турындагы ышануларның бик аз сакланган булуы татар халкының мифологик системасын өйрәнүчеләр алдында кыенлыклар китереп чыгара. Халыкның мифологик күзаллауларын ачыклау юнәлешендә төп чыганак булып түбән мифологиягә караган ияләр, рухлар турындагы ышанулар, әйләнә-тирә дөнья турындагы карашлар төп чыганак ролен үти. Татар халкының гына түгел, башка халыклар мифологиясе дә мифологик персонажлар турындагы күзаллаулар, алар белән бәйле мотив, функцияләрне үз эченә алган катлаулы система

буларак билгеләнә. Өйрәнү объектын тәгаенләштерү материалның чикләрен дә киңәйтеп җибәрә. Мифологик персонажларга бәйле традицион рәвештә өйрәнелә торган жанрлардан (сөйләкләр, әкият, риваять, легенда) тыш, эзләнүләр барышында ырым текстларын, йола гадәтләрен (йорт иясен яңа йортка күчерү, йорт иясенә ризык кую, җен алыштырган баланы кайтару, йорттан җен куу һ.б.), көндәлек тормыш белән бәйле гадәтләрне (су аркылы чыкканда җеп ташлау; мунчада әйбер калдырып чыгу, җен төкермәсен өчен ризык өсләренә ябу һ.б.) ышану, тыюлар, табышмак, мәкаль, әйтем кебек жанрларны исәпкә алу да бик мөһим.

Бер локаль традициягә хас булган мифологик күзаллауларны туплаганда, персонажның (күренешнең) исеме, кыяфәте, җенесе, күренү урыны, вакыты, танып булу мөмкинлеге, аның функцияләре, кешегә булган мөнәсәбәте, кешенең аңа карата кылган гамәлләре һ.б. барланырга тиеш. Мифологик персонажны бу юнәлештә өйрәнү схемасы 1980 елларда Россия Фәннәр академиясенең Славян белеме һәм балканистика институты галимнәре тарафыннан эшләнгән иде [Виноградова, с. 40–44]. Эзләнүләрне әлеге юнәлештә алып барганда, билгеле бер локаль традиция өчен хас булган күзаллаулар системасын ачыклау мөмкинлеге туа. Бу, үз чиратында, чагыштырма анализ өчен җирлек булып тора һәм татар халкының билгеле бер этник төркеменә караган фольклорда барлыкка килгән төрки нигезле һәм алынма элементларны ачыкларга мөмкинлек бирә.

Биредә тәкъдим ителә торган сораулык югарыда әйтелгән үзенчәлекләрне истә тотып төзелде, һәм ул экспедицияләрнең уңай тәҗрибәсенә нигезләнгән материалларны үз эченә ала. Әлбәттә, әлеге сораулар татар халкының мифологиясен тулаем бер система буларак өйрәнүдә беренче адым гына, аны алга таба җыелачак материалларга таянып тулыландырырга, татар халкының башка этнотерриториаль төркемнәренә яраклаштырырга кирәк. Кулланылыш даирәсе ягыннан сораулык Урта Идел буенда яшәүче татарларны күз алдында тотып төзелгән. Бу, әлбәттә, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә аны кулланырга ярамый дигән сүз түгел, әмма башка төбәкләрдә эш алап барганда, сораулар исемлеген җирле үзенчәлекләрне истә тотып тулыландыру сорала.

**Әйләнә-тирә дөнья**

1. Дөнья кайчан һәм ничек барлыкка килгән?

2. Без яши торган дөнья барлыкка килгәнче нәрсә булган?

3. Дөнья ничә өлештән тора? Күк, җир, җир асты дөньялары юкмы?

4. Күктә кем дә булса яшиме? Күкнең хуҗасы бармы? Күктә булган кешеләр турында сөйләмиләрме?

5. Күкне җир белән нәрсә тоташтыра?

6. Күк капусы нәрсә ул? Күк капусы ачылса, нәрсә була?

7. Яңгыр, кар, күк күкрәү кебек табигать күренешләрен кем

булдыра? Күк хуҗасымы ул, әллә аларның һәрберсенең хуҗалары бармы? Күккә атап нәрсәләр әйтәләр?

8. Кеше яңгырны, карны туктата аламы? Бик куркыныч килә торган яңгырны ничек дип атыйлар? Аны туктатыр өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? (ишек алдына көрәк, табагач ташлау, таяк белән селтәнү, догалар уку). Яңгыр булмаса, кояш чыкмаса, балалар нәрсәләр әйтәләр?

9. Яшен суккан кешеләр турында сөйлиләрме сездә? Яшен суккан кешене нишләтәләр? Яшен кайдан килеп чыга? Кемне сугарга мөмкин? Гөнаһлы кешене түгелме?

10. Беренче яшенне ишеткән кеше нишләргә тиеш (җирдә тәгәрәү, таш ату, юыну һ.б.)? Яшеннән курыкмас өчен нишлиләр? Яшен суккан агачның аерым исеме булганмы? Андый агачтан йорт салырга ярыймы? Яшеннән кайда качып була? Ничек сакланырга кирәк (ишек, тәрәзәләрне ябу, тәрәзәләргә ботаклар элү һ.б.)?

11. Озак вакытлар яңгыр яумаса, нишләргә кирәк? Яңгыр боткасы пешерү, авылны әйләнеп җир сөрү, кырмыска оясына су сибү һ.б. Аларны ничек башкаралар?

12. Корылык булса, үлгәннәргә мөрәҗәгать итмиләрме? Зиратта дога кылу, үз үлеме белән үлмәгән кешеләрнең каберләренә су салу гадәте юкмы? Корылык булмасын өчен нәрсәләр эшләргә кирәк?

13. Аҗаган нәрсә ул? Аны күргән кеше юкмы? Күргән кеше белән берәр хәл булмыймы? Ни сәбәпле була ул?

14. Яңгырдан соң чыккан салават күперен ничек аңлаталар? Ни өчен чыга ул? Аның өстендә кем дә булса йөрмиме? Ике башында Хозыр белән Ильяс утыра дип әйтмиләрме?

15. Җир асты дөньясы бармы? Анда кереп буламы? Тере кешеләр керә аламы анда? Үлеләрне ни өчен шунда күмәләр? Җир астына төшеп кире кайткан кешеләр турында сөйлиләрме сездә?

16. Җир асты дөньясының хуҗасы бармы? Аны ничек атыйлар? Нәрсәләр эшли ул? Җир тота дип әйтмиләрме сездә?

17. Җир Анасы бармы? Беренче тапкыр чәчүгә чыкканда, аңа мөрәҗәгать иткәннәрме? Җиргә нәрсә сипкәннәр (йомырка, ипи һ.б.)? Беренче буразна алдыннан суканы май белән сөртәләрме? Чәчүгә иң алдан чыккан кешегә авыл кешеләре йомырка бүләк иткәннәрме? Игенче нинди сүзләр әйткән?

18. Утның җаны бармы? Аның иясе бармы? Утның балалары бармы? Утка атап берәр нәрсә әйтмиләрме? Утны үрләтер өчен нәрсә дигәннәр? Утка тырнак якканда нәрсә дип әйтәләр? Утка ризык салмыйлармы? Утны йолаларда кулланалармы (яшьләрне ут аша сикертү, кешене җирләп кайтканнан соң мичкә ягу, яшь киленнең мичкә кагылуы һ.б.)? Ут җеннәрдән саклыймы?

19. Кеше кайдан барлыкка килгән? Кем ясаган аны? Хәзерге кешеләргә хәтле Алыплар булган дип әйтмиләрме сездә? Кешегә җанны кем өргән? Яхшы һәм начар кешеләрне, ир-ат һәм хатын-кызларны аерым ясамаганнармы?

**Иябр, түбән рухлар**

20. Табигатьтәге төрле күренешләрнең ияләре бармы? Нәрсәләрнең ияләре була? Алар ничек барлыкка килә? Таш, кое, чишмә ияләре бар дип әйтмиләрме сездә?

21. Сездә йорт иясен ничек атыйлар? (йорт иясе, йорт хуҗасы, нигез хуҗасы, кырсут). Ул кешегә күренәме? Нинди кыяфәттә күренә? (кеше, хайван, әйбер). Йорт җыланы бар дип әйтмиләрме сездә? Йорт иясен ничек танып була? (яше, буе, киеме, тышкы кыяфәте, тән зәгыйфьлеге)?

22. Йорт иясе кайда яши (идән асты, мич, йорт почмаклары)? Сез аны ашатасызмы? Ашатсагыз, нәрсә ашатасыз (ботка, ипи һ.б.)? Ризыкны ничек әзерлисез, аның күләме? Аны ничек ризалатасыз? Аңа атап дога кыласызмы, сәдака бирәсезме?

23. Кайсы вакытта кешегә күренә ул? Төнлә чыгып нәрсә дә булса эшләп йөрмиме (савыт-саба шылтырата, йон эрли, елый, бәла киләчәген хәбәр итә һ.б)? Ул йөргәндә нинди авазлар ишетелә?

24. Йортта ызгышсаң, сызгырсаң, йорт иясе ташлап китә дип әйтмиләрме?

25. Йорт иясенең гаиләсе, балалары бармы? Йортта ул ничек барлыкка килә? Аны үстереп буламы? Ата-бабаларның үлгәннән соң кайткан җаны түгелме ул?

26. Яңа йортка күчкәндә йорт иясен күчерәсезме? Ничек күчерәсез? Иске йорттан чыгып китәр алдыннан сез аны ничек чакырасыз? Үзегез белән нәрсә дә булса аласызмы? Көннең кайсы вакытында күчерәсез? Аны алып барганда сөйләшергә ярыймы? Яңа йортта нигез боткасы пешерәсезме? Йорт иясен күчермәсәң, нәрсә була? Төп йорттан башка чыкканда, яңа өйдә йорт хуҗасы ничек барлыкка килә? Күчермәсәң, ташландык нигездә елап утыра дип әйтмиләрме аны?

27. Йорт иясе кешегә ярдәм итәме? Ничек ярдәм итә (көтүгә уята, киләчәкне юрый, йорт эшләрен эшли, авырулардан саклый)? Йорт иясе нәрсәгә кирәк? Ул булмаса, йорт нишли?

28. Кешегә зыян салмыймы ул? Йоклаганда баса дип әйтмиләрме аны? Хатын-кызлар белән яшәмиме ул? Югалган әйберне эзләргә булышмыймы?

29. Мунча иясе бармы? Аның кыяфәте нинди? Елан, мәче кыяфәтендә күренмиме ул?

30. Мунчада ул кайда яши? Кергәндә, аның белән исәнләшергә кирәкме? Чыкканда рәхмәт әйтәләрме? Аның өчен чиста сөлге элеп куймыйлармы? Мунчаны чиста тотарга кирәкме? Нинди утын яксаң, мунча иясенең ачуын чыгарасың? Мунчага кайсы вакытта керергә ярамый? Ярамаган вакытта керсәң, мунча иясе нишләтә? Элек баланы мунчада тапмаганнармы? Мунча иясе балага тимиме? Җен алыштырган баланы кире кайтарыр өчен мунча тупсасына салып кыйнамыйлармы?

31. Мунча иясе үзен ничек белдерә? Ул мунчада нәрсәләр эшли? Мунча иясенә ризык куяларммы?

32. Кияү мунчасы кергәннән соң, мунча иясенә бирәр әйбер

калдыралармы? Мунча иясенә атап сүз әйтәсе түгелме?

33. Мәетне мунчага алып керергә ярыймы? Аны юар өчен кирәк булган әйберләрне мунчадан алырга ярыймы? Мунчада дога кылырга ярыймы? Элек озак авырган кешене мунчага кую гадәте булмаганмы?

34. Ташландык мунчаларда җеннәр җыелмыймы? Алдагы тормышны юрау ырымнарын мунчада башкармыйлармы? Мунчада кычкырышырга ярыймы?

35. Хозыр Ильяс кем? Нинди кыяфәттә була ул? Аның Хур кызы исемле сеңлесе бар дип әйтмиләрме?

36. Кайда очрый ул кешегә? Хозыр Ильяс юлда йөри дип әйтмиләрме? Юлчыларга ярдәм итәме ул?

37. Хозыр Ильяска корбан бирү гадәте юкмы? Бәрәңге казыганда берничә төпне казымыйча калдырмыйлармы? Җир сөргәндә, әйбер утыртканда Хозыр Ильяска мөрәҗәгать итәләрме?

38. Хозыр җир иясе, Ильяс су иясе түгелме? Хозыр Ильяс ул бер үк кешеме? Хозыр Ильяс йорт хайваннарын саклыймы? Ул абзарда яшәмиме?

39. Хозыр Ильяс камчысын селтәсә, яз килә дип әйтмиләрме? Су аркылы чыкканда, Хозыр Ильяс кырга ташласын, дип әйтмиләрме?

40. Беренче көтү куганда, Хозыр Ильяска мөрәҗәгать итмиләрме? Хәер биреп (сөт өсте, сөт, йомырка) дога кылу гадәте юкмы?

41. Юлчыларга ул кайсы вакытларда очрый? Ничек ярдәм итә?

42. Йортыңа карт кеше, хәерче килеп керсә, аны борып чыгарырга ярыймы? Куып чыгарган кешеләрне Хозыр Ильяс каргый икән дип әйтмиләрме?

43. Су хуҗасы, Су иясе бар дип әйтәләрме? Ул нинди кыяфәттә була? Ир-атмы, хатын-кызмы? Су иясе кеше, хайван кыяфәтенә керә аламы? Су сыеры, я Кара Үгез бармы? Судан хайван кыяфәтендә чыгалармы алар? Кайда яшиләр? Кеше йөрмәгән елгаларда түгелме? Төнлә тавышы ишетелсә, нәрсә аңлата?

44. Су аркылы чыкканда, нәрсә дип әйтәсез? Яшь киленгә су юлы күрсәтәләрме?

45. Су иясе нәрсәләр эшли (үзенә тартып ала, кешене су тота)? Су тотканда кайсы урын авырта?

46. Су иясен ничек ризалатасыз (дога кылу, суга җеп, яфрак агызу, суга корбан бирү, тоз, ярма сибү)?

47. Елга буена чыгамы ул? Чәчен тарарга чыкканын күргән кеше бармы? Күргән кешегә нәрсә була?

48. Төнлә су коенырга, су эчәргә ярыймы? Кызларга кояш баегач, елга ярына төшәргә ярыймы?

49. Су иясе кайда яши? Кыш көне кая китә? Су иясенең гаиләсе, балалары бармы?

50. Суга әйбер салу, корбан бирү гадәте бармы? Корбан бирмәгән кешегә нәрсә була? Яз көне ташу киткәннән соң, суга корбан бирәсе түгелме? Су коена башлагач, Су иясе бер кешене үзенә ала дип әйтмиләрме?

51. Суга беренче тапкыр яңа көймә төшергәндә, Су иясенә әйбер бирү гадәте бармы? Балык күп тотылсын өчен нишләргә

кирәк? Балыкчы балыкны башкалардан күбрәк тота торган булса, ул кеше турында нәрсә диләр?

52. Мал иясен ничек атыйлар (мал иясе, сарай иясе, Пәша Ана, Зәнги баба, Гамбәр Ана һ.б.). Кош-кортларның, эре терлекнең ияләре аерыммы?

53. Мал иясе кайда яши? Абзарга кергәндә, исәнләшеп керәсе түгелме?

54. Мал иясенә атап корбан чалмыйсызмы? Аңа ризык куймыйсызмы? Маллар кысыр калса, иягә атап әйбер бирәсезме?

55. Зәнги бабага атап угыз боткасы пешермисезме? Хайваннарга ашатыламы ул?

56. Гамбәр ана бар дип әйтмиләрме сездә? Кошка әверелә, хатын-кызларны яклый димиләрме аны? Кош рәвешендә улын эзли икән дип әйтмиләрме? Аңа дип, яз көне киртә башларына ризык куеп чыкмыйлармы?

57. Мал иясе йортта ни өчен кирәк? Ул хайваннарга нинди очракларда ярдәм итә? Нинди очракларда зыян сала? Хайван килешә-килешми дип ничек юрыйсыз?

58. Яңа йорт салып чыкканда яисә яңа абзар төзегәч, Мал иясен күчермисезме?

59. Йорт хайваннары ничек барлыкка килгән? Алар арасында изгеләре бармы? Ашарга ярамаган хайваннар бармы?

60. Урман иясе буламы? Ул нинди кыяфәттә, кайчан күренә?

61. Урманга кергәндә Урман иясе белән исәнләшү, аннан рөхсәт сорау гадәте бармы? Урманга кергәндә Урман иясенә атап теләкләр әйтелмиме? Урман иясенә ауга баргач, бүләк калдыру гадәте юкмы? Аңа бирәр әйбер калдырасы түгелме (сәдәп, җеп)?

62. Урман иясе аучыга күренәме? Урман иясе кешеләрне адаштырмыймы? Урманда кычкырып сөйләшергә ярыймы? Аучыларга бер-берсенең исемен атарга ярыймы? Хайваннарның исемен әйтергә ярыймы?

63. Урманда ятып йокларга ярыймы? Кече йомышны йомышларга ярыймы? Урманда кунарга кирәк булса, Урман иясеннән рөхсәт сорарга кирәкме? Башны капламыйча урманга керергә ярыймы?

64. Урманда җиләк җыйганда әйтелә торган махсус сүзләр юкмы?

65. Шүрәлене күргән кеше юкмы? Шүрәле кем ул – Урман иясеме? Шүрәледән ничек качып була? Очраса, кешеләрне нишләтә ала?

66. Шайтан нәрсә ул? Нинди кыяфәттә? Кайда очрый? Нинди гамәлләр кыла? Су өсләрен төнгә ачык калдырсаң, шайтан төкергән димиләрме?

67. Шайтан кешеләргә, йорт хайваннарына тимиме? Кайда очрый? Йорт хайваннары авырса, аларга шайтан тигән димиләрме?

68. Албасты нинди кыяфәттә була? Кайда очрый? Аны ничек танып була? Ул кешегә зыян кыламы? Бала тапкан аналарның балаларын алмыймы ул? Йоклаган кешеләрне нишләтә? Авырлы хатыннарга тияме?

69. Албастыдан ничек котылырга мөмкин? Бастырылганда нәрсә дип әйтергә кирәк?

70. Сездә адаштыра торган урыннар бармы? Кем адаштыра анда? Кайсы вакытта очрый ул?

Нинди кыяфәттә очрый? Берәр тавыш чыгармыймы? Аны ничек дип атыйлар? Бу урынның исеме ничек? Нинди ул? (юл чаты, урман уртасы). Җен белән очрашкач нишләргә кирәк? (киемне әйләндереп кияргә, сүгенергә). Нинди кыяфәттә күренә ул? (ут, печән чүмәләсе). Кешегә очрагач, ул аны нишләтә? Бозамы, чирләтәме?

71. Баланы ана карыныннан урлау очраклары булганмы? Аны ничек дип атаганнар? «Җен алыштырган» димәгәннәрме? Кире кайтарыр өчен нәрсә эшләргә кирәк? «Алмаштырылган» бала үзен ничек тота? Ул яши аламы? Тумаган баланы анасының карыныннан урлау очраклары булганмы? Булса, халык аны кем урлаган дип әйтә? Баланы җен алыштырмасын өчен нәрсә эшләргә кирәк? Карында үлгән бала яисә үле туган бала турында нәрсә diләр? Ул җенгә әйләнмиме? Алыштырган баланы кире кайтарып буламы?

72. Төнге уникедә мунча керергә ярыймы? Җеннәрнең кешене мичкә тыгып кую очраклары булмаганмы? Зәхмәт кагылган дип әйтмәгәннәрме? Җеннәр мунчада пәри туе үткәрмәгәннәрме?

73. Җен ничек барлыкка килә? Бәдрәфтә туалар, дип әйтмиләрме? Хайван күмелгән урын зәхмәтле урын түгелме? Канлы, әшәке урыннарга җеннәр җыела дип әйтмиләрме?

74. Төнлә урамда йөрергә ярыймы? Кемнәрне очратырга мөмкин?

75. Урамдагы җил өермәләрен җен туе, пәри туе дип әйтмиләрме? Кеше яши торган йортка җеннәр керә алмыймы? Керсә, аны ничек куып чыгарырга мөмкин? (мылтык ату). Җен кермәсен өчен нишләргә кирәк? (ризыкның өстен каплау, тәрәзәләрне каплау, морҗа тишекләрен ябу).

76. Урамда тузан өермәсен күрсәң, аны нәрсә дип әйтәләр? Җен өермәсе дип атамыйлармы?

77. Убыр бар дип әйтмиләрме сездә? Ул нинди кыяфәттә була? Кайчан күренә? Убыр сихерчеләр яисә үз-үзләрен үтерүчеләрнең җаны түгелме?

78. Убыр кешеләрнең, хайваннарның канын эчмиме? Аның белән очрашсаң, исән калып буламы? Кешеләрне бозмыймы ул?

79. Сыерларның сөтен имә димиләрме аны? Балаларны ана карыныннан урламыймы? Ирләргә бәйләнмиме? Юлларда кешеләргә очрап, аларны адаштырмыймы?

80. Убыр җеннәр белән очрашмыймы? Белемнәрен кайдан ала? Кеше ничек Убырга әйләнә? Убырны ничек танып була? Ул хайван кыяфәтендә йөрмиме? Ут кыяфәтендә морҗа тишегеннән чыгып йөри димиләрме?

81. Убыр кайсы вакытта кешегә күренә? Хатын-кызмы, әллә ир-атмы ул? Хатыны Убыр икәнен ире белеп яшиме? Убыр аңа зыян салмыймы?

82. Убырдан ничек сакланып була? Аны күрсәң, нишләтергә кирәк? Үлгәннән соң Убыр нишли? Яңадан чыгып йөри аламы ул? Үлгәч, кем Убырга әйләнергә мөмкин (сихерчеләр, кеше үтерүчеләр, балаларны яратмый торган кешеләр)?

83. Үле кешенең Убыры чыга, дип әйтмиләрме? Убыр тереneke, үленеке булмыймы?

84. Зират иясе бар дип әйтәләрме? Зиратта кем дә булса яшиме (җен, гаип ирәннәр)? Зиратка кергәндә нәрсә дип әйтергә кирәк? Көлергә, кычкырып сөйләшергә ярыймы? Төнлә зиратка керсәң, нәрсә була? Хатын-кызга кайсы вакытта керергә ярамый? Зираттан чыкканда, нәрсә дип китәргә кирәк? Борылып карарга ярыймы? Адашкан кешене, атны керәшен зираты тирәли әйләндермиләрме?

**Гадәттән тыш сыйфатларга ия кешеләр**

85. Сездә кешеләргә бозым сала торган, чир китерә торган кешеләрне ничек атыйлар? Алар нинди була? Белемнәрен кайдан ала? Кешеләргә карата нинди гамәлләр кыла? Сихерчеләр хайваннарга әйләнә аламы? Кешеләрне, хайваннарны боза аламы алар? Бозсалар, нәрсә белән боза? Кемнәрне боза? Кемне дә булса бозган очраклар бармы? Бозымны ялгыш кына алган кешеләргә нәрсә була? Белемнәрен ничек итеп икенче кешеләргә тапшыра? Үлә алмый азаплана дип әйтмиләрме аларны? Нинди дә булса хайванга әверелә алмыйлармы алар? Сихерче җил өермәсе белән очып йөрмиме?

86. Төрле авырулардан дәвалый торган кешеләрне ничек атыйлар? Имче карчык димиләрме аларны? Алар кешеләрне, хайваннарны терелтәме? Авылга корылык, пожар, куркыныч авырулар килсә, ул ничек ярдәм итә ала? Бозымны кайтара аламы ул? Берәр әйберне югалтсаң, хайван югалса, табып бирәме? Алга таба нәрсә булачагын әйтә аламы? Андый кешеләрне күрәзәче димиләрме? Кешеләргә ничек ярдәм итә ул? Төшләрне юрый беләме?

**Җан, үлеләр дөньясы**

87. Кешенең җанын ничек атыйсыз? Кеше үлгәч, аның җаны кая китә? Җан кайда була (каш арасында, йөрәктә)? Кеше исән вакытта аның җаны чыгып йөри аламы? Кешенең ничә җаны бар? Кот нәрсә ул?

88. Үлгән кешенең җаны ничек чыга? Җан чыкканын ничек белеп була? Җан чыккач, кая китә (соңгы тамчы су белән)? Теге дөньяга җан китәме, тәнме? Җан да үлә аламы?

89. Мәетнең җаны кайтып йөри дип әйтәләрме? Нинди кыяфәттә кайта (кош, күбәләк)? Кайчан кайта? Нәрсә өчен? Кайсы вакытта?

90. Карындагы баланың җаны бармы? Ул аңа кайчан иңә?

91. Күләгә нәрсә ул? Күләгә кеше тугач барлыкка киләме? Ул кешедән башка яши аламы? Кеше үлгәч, ул кая китә?

92. Йокы нәрсә ул? Йоклаганда кешенең җаны чыгып йөриме? Кеше йоклаганда ни өчен йөри? Аңны югалту вакытында нәрсә була? Мәрткә китү нәрсә ул?

93. Ни өчен игез балалар туа? Аларның икесенә бер җан, дип әйтмиләрме? Игез бала туса, аларны нишләтәләр? Куш багана төбенә куймыйлармы, тәрәзәдән бирмиләрме һ.б.

94. Ни өчен кеше авырый? Авыруны төрле чир ияләре кешегә кертә, дип аңлатмыйлармы? Нинди авырулар ияле була?

95. Үлем нәрсә ул? Ул күзгә күренәме? Аерым зат түгелме ул? Кешенең яшәү вакытын кем билгели?

96. Үлгән кешене ничек атыйсыз (әрвах, мәет)? Кеше үлгәч, я хайванга, я кошка әверелә, дип әйтмиләрме? Кеше берничә тапкыр туа аламы?

97. Үлгән кеше төшкә керәме? Ни өчен керә? Кермәсен өчен нишләргә кирәк (киемнәрен тарату, сәдака бирү)?

98. Мәеттән куркырга кирәкме? Ул кешегә зыян сала аламы? Күмәргә алып барганда, артыннан хатын-кызга барырга ярыймы? Таяк ташлап калдыра дип әйтмиләрме? Авылны чыккач мәетнең юлын бутау гадәте юкмы? Мәетне озатып кайткач, өйдә нинди гамәлләр кылырга кирәк (утын алып керү, мич ягу, морҗа ачу һ.б)?

99. Үле туган баланың җаны буламы? Үлгән баланы кем өйдән алып чыга? Анасына зиратка барырга ярыймы? Үлгән балаларның җаны кая китә? Үлгән баланың җаны изге дип әйтмиләрме? Бала тапканда үлгән хатын-кыз кайтып йөрмиме? Кешеләргә начарлык кылмыймы ул?

100. Карындагы баланың җаны бармы? Аңа җан кайчан иңә? Аның махсус атамасы юкмы? Үле туган баланың яисә тугач та үлгән баланың җаны кайтып йөрмиме? Аның елаган тавышы ишетелмиме? Туганда башка кешеләргә кайсыдыр ягы белән охшамаган кеше, үлгәч явыз рухка әйләнмиме (ике йөрәкле, күлмәктә туганнар, кыпкызыл булып туганнар)?

101. Үлгән кеше кире кайтып йөриме? Кемнәр кайта? Ни өчен кайта? Үлгән кешенең җаны кайтуга ризык әзерлисе түгелме? Ишекләрне ачып куясы түгелме? Ничә көн кайтып йөри ул? Йорт капкасына җан адашмасын өчен билге куясы түгелме?

102. Мәет юган суны кая түгәргә кирәк? Мәет үлгәч, кайтып йөрмәсен өчен, нишләргә кирәк (киемен кире ягы белән тегәргә, тәрәзә, көзгеләрне капларга, идәнне түргә таба юарга, өйдән алып чыкканда, аягын алга каратып алып чыгарга)? Кеше үләргә ятканда, ишекләрне бикләргә ярыймы? Әрвахлар кешеләргә яхшылык эшлиме, начарлыкмы? Сихерчеләрнең, үз-үзләрен үтерүчеләрнең җанын ничек атыйсыз?

103. Үз үлеме белән үлмәгән кешеләр кемнәр алар? Аларны ничек атыйлар? Әгәр дә мәете табылмаса, аның урынына хайван күмү гадәте булмаганмы? Кеше үлгәч, корбан чалмаганнармы? Югалган кешене ничек эзләгәннәр? Кемнәр кайтып кешеләргә начарлык кылып йөри? Нинди очракларда кайталар (үлгәннән соң елап искә алынган, дөрес итеп күмелмәгән, киеме белән күмелмәгән, үз-үзенә кул салган кешеләр, кемдер тарафыннан үтерелгән кешеләр). Андый кешеләрнең җаны куркыныч дип әйтәләрме? Аларны күмгәндә балаларга, хатын-кызларга яннарында торырга ярыймы?

104. Үлгән кеше үзе кайтамы, җанымы, яисә үлгән кеше сурәтендә җен килеп йөриме? Кайчан кайтып йөриләр (40 көн, 6 атна, 1 ел яисә төнлә, 12 дә һ.б.)? Кире кайткан мәетләр кайда очрый? Өйдә, юлда, үтерелгән җирендә? Тереләр дөньясына ни-

чек керәләр (мич торбасыннан, кабер тишегеннән һ.б)?

105. Нинди кыяфәттә киләләр (кеше, хайван, өрәк, утлы елан, пәри һ.б.)? Киемнәре буламы? Алар арасында яхшылары бармы? Аналары үлсә, балалары янына кайта, дип әйтмиләрме?

106. Кайткач нишлиләр (куркыталар, ярдәм итәләр, тынычлык бирмиләр)? Җен булып үлгән ире кайтмыймы? Ул Утлы елан кыяфәтендә күренмиме? Кайтып йөрмәсен өчен нишләргә кирәк (иреңнең эчке киемен кию, өйгә әйберләр элү, ярма сибү, юл бутау, кабергә тишек тишү, төнге уникедә чәч тарау)? Кайткан мәеттән ничек саклыналар (өй тирәли, кабер тирәли тары сибү, үлән белән төтәсләү, көмеш әйберләр кую, кабергә усактан ясалган таяк тыгу, хәер бирү)?

107. Өрәк кем ул? Үлгән кешенең канныннан барлыкка килмиме ул? Үлгән кеше кыяфәтенә кереп йөрүче җен түгелме ул? Ул нинди кыяфәттә була? Нинди киемнән йөри? Йоклаган кешеләргә тимиме ул?

**Әдәбият**

*Бакиров М.Х.* Татарский фольклор. Казан: Ихлас, 2012. 400 с.

*Виноградова Л.Н.* К проблеме идентификации и сравнения персонажей славянской мифологии / Л.Н. Виноградова, С.М. Толстая // Славянский и балканский фольклор. Верования. Текст. Ритуал. М., 1994. С. 16–44.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. Казан: Мәгариф, 2008. Т. 1 (А–Г). 303 б.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*